КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 6 февраль г.Казань № 79

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия юристлары ассоциациясе» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсенә устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм хокукый белем бирү өлкәсендә чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 16 гыйнвар, 10 нчы карары белән расаланган «Россия юристлары ассоциациясе» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсенә устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм хокукый белем бирү өлкәсендә чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия юристлары ассоциациясе» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсенә устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм хокукый белем бирү өлкәсендә чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 16 гыйнвар, 10 нчы карары белән расаланган «Россия юристлары ассоциациясе» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсенә устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм хокукый белем бирү өлкәсендә чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән

тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «финанс елына һәм план чорына» сүзләрен «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» дәүләт программасын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 20222 елларга Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 13 сентябрь, 656 нче карары белән расланган «2014-20222 елларга Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыруга финанс елына һәм план чорына» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктның дүртенче абзацында «банкротлык» сүзен «аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, Россия юристлары Ассоциациясенең Татарстан бүлеге эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия юристлары Ассоциациясенең Татарстан бүлеге үзгәртеп кору, бетерү процессында булмавы, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәве, аның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмавы һәм ул әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан башка норматив хокукый актлар нигезендә акча алмавы турында Россия юристлары Ассоциациясенең Татарстан бүлеге җитәкчесе имзалаган белешмә.»;

9 пунктның өченче абзацында «Россия юристлары ассоциясенең Татарстан бүлекчәсе тарафыннан тәкъдим ителгән мәгълүмат» сүзләрен «Россия юристлары ассоциясенең Татарстан бүлекчәсе тарафыннан тапшырылган документларда булган мәгълүмат» сүзләренә алмаштырырга;

12 пунктта «субсидиядән файдалану турында хисап бирү сроклары һәм рәвешләре» сүзләрен «субсидияләр бирү нәтиҗәсе, субсидиядән файдалану турында, шул исәптән аны бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап бирү тәртибе, сроклары һәм формасы, министрлык тарафыннан Россия юристлары ассоциясенең Татарстан бүлекчәсе тарафыннан өстәмә хисап бирү срокларын һәм рәвешләрен билгеләү хокукы» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $12^1$ пункт өстәргә:

«$12^1$. Субсидия бирү нәтиҗәсе булып Россия юристлары Ассоциациясенең Татарстан бүлегенең устав эшчәнлеген гамәлгә ашыру һәм хокукый белем бирү өлкәсендә вакыт эчендә чаралар үткәрү тора

Субсидия бирү нәтиҗәсе булып Россия юристлары Ассоциациясенең Татарстан бүлегенең устав эшчәнлеген гамәлгә ашыру һәм хокукый белем бирү өлкәсендә «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» дәүләт программасын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип тану турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 13 сентябрь, 656нче карары белән расланган «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» дәүләт программасының «2014-20222 елларга Татарстан Республикасында юстиция өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру» ярдәмче программасына кушымтаның 7.3 пункты белән расланган вакыт эчендә чаралар үткәрү тора.»;

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Россия юристлары Ассоциациясенең Татарстан бүлеге квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр, Министрлыкка субсидияләрдән файдалану, шул исәптән субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешү турында, кушымта нигезендә хисап бирә.»;

Тәртипкә кушымта өстәргә (теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

«Россия юристлары ассоциациясе» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсенә устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм хокукый белем бирү өлкәсендә чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә кушымта

Форма

20__ елның ____________
«Россия юристлары ассоциясе» бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлегенең субсидияләрдән файдалану, шул исәптән субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешү турында
ХИСАБЫ

(сум)

| № | Субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешү | Чыгымнар юнәлешләре | Бүлеп бирелгән субсидия күләме | Хисап чоры башына субсидияләр калдыгы | Хисап чорында касса чыгымнары | Касса чыгымнарын раслый торган документларның исеме, реквизитлары (номеры һәм датасы) | Хисап чоры ахырына файдаланылмаган субсидия калдыгы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |

Җитәкче ___________/_____________________
(имза) (инициаллар, фамилия)

Баш хисапчы ___________/_____________________ ________________________________
(имза) (инициаллар, фамилия) (телефон)

М.У.

20 __ ел, «___» ________________

________________________________